


Ел саен, гадәттәгечә, беренче сентябрьдә Белем конен бәйрәм итә идек. Быел, Россия Федерациясе буенча, ул кон 2 сентябрьдә vтте, чонки 1 сентябрь ял коненә туры килде. Шул конне чәчәкләр тоткан балалар, дулкынланган ата-аналар һәм укытучылар мәктәпкә ашыкты. Бәйрәм унаеннан, анын тарихы һәм vзенчәлекләре белән танышып китик әле. Мәктәптә уку еллары – кеше гомеренен ин мавыктыргыч, бай һәм онытылмас чоры. Бәйрәмнен барлыкка килvен рәсми рәвештә 1984 елдан исәплиләр. Әмма бәйрәм vзе 1930 елда мәҗбvри белем бирv турындагы законны кабул итv белән vк барлыкка килгән. Мона кадәр уку елы башланунын катгый датасы булмаган.

Россия империясе вакытында шәһәр укучылары август ахырында, сентябрь башында, ә авыл укучылары 1 декабрьдә укуга керешкәннәр, чонки авыл балалары барлык кыр эшләре тәмамлангач кына, мәктәпкә йори алган. 1984 елнын 1 сентябренә кадәр барлык мәктәпләрдә дә тантаналы линейкалар, аннан сон «Тынычлык дәресе» һәм башка дәресләр vткәрелгән, ягъни бу бер тулы уку коне булган. Ә хәзер 1 сентябрь бары тик тантаналы рәвештә генә уза, барлык укучылар да чәчәк бәйләмнәре белән, мәктәп формасыннан килә. Тантананын топ мизгеле – беренче кынгырау. Кынгырау чыны яна уку елы башлануны билгели.
Белем конендә Мордовия Респуб-ликасынын 231 мәктәбе vз парталары артына 74012 укучыны кабул итте. Беренче тапкыр мәктәп бусагасын 6808 бала атлады. Шулай, 2 сентябрь конне Рузаевка районында мәктәп парталары артына 6247 укучы утырды. Ә Беренче кынгырау 561 беренче сыйныф укучысына янгырады. Безгә якын булган Татар Пешлә урта мәктәбенен ишекләрен беренче тапкыр ачып, беренче сыйныфка 11 укучы

килде. Ә барлыгы бу ремонтланган матур мәктәп бинасында 199 укучы белем алачак, ди мәктәп директора Флора Әхмәтжан кызы Шамонова, тантаналы линейканы vткәргәч. Ә Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе директоры Надия Харис кызы



Заликова әйткәнчә, барлыгы 2024-25 уку елында Пензятка урта мәктәбендә 128 укучы белем алачак: аларнын 17 – беренче сыйныфта, ә бишесе 10 сыйныфка килгәннәр. Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе директоры Татьяна Анатольевна Кадрякова белән мәктәпләрендә беренче уку елы башлану коне турында сойләштек. Әйтеп китик, мәктәпнен унышлары сокландырырлык. Мәсәлән, Латышовка урта мәктәбендә ана телен укытуга зур урын бирелә. Укучылары торле чараларда – татар теле һәм әдәбияты буенча vткән регион, регионара, халыкара олимпиадаларында, конкурсларда жинvләр яулыйлар, ә укытучылары Светлана Равиль кызы Поташова vзе дә, торле чараларда катнашып, жинvләр яулый. Быел 10 сыйныф укучысы Курмакаев Владимир июнь аенда Казанда vткән рус теле буенча халыкара олимпиадасынын «Звучащее слово» номинациясендә жинv яулаган. Башка унышлары да соендерә бу мәктәп укучы һәм укытучыларынын. Бvген сvзебез Белем бәйрәме турында. Татьяна Анатольевна болай дип әнгәмәне дәвам итте:
- 2024-25 уку елында Латышовка урта мәктәбебездә 32 укучы белем алачак. Шулар арасында Большие Поляны топ мәктәбеннән, Адашеводан, Паеводан, Глушкcodан берәр укучы бар. Әмма, кызганычка каршы, Россиядә булган жәмгыяви vзгәрешләр нәтижәсендә, быел беренче сыйныф укучыбыз юк. Икенче сентябрь конне барлык атрибутлары белән традицион тантаналы линейкадан башладык. Аннары сыйныф житәкчеләре, укучылары белән бергә, киләчәк турында «Образ будущего. Ко Дню знаний» темасына дәресләр vткәрделәр.



Шул ук районнын Большие Поляны топ мәктәбендә, тантаналы Белем конендә, 1 сыйныфка ике укучыны кабул итеп, яна мәктәп тормышы башлану белән котладылар. «Мәгариф» милли проекты, «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында, бу мәктәп базасында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле мәгариф vзәген ачу тантанасы да булды. Авыл жирендәге һәм кече шәһәрләрдәге гомуми белем бирv оешмалары базасында «Үсеш ноктасы» vзәкләре гомуми белем бирvнен сыйфатын яхшырту очен шартлар тудыру очен тозелә. «Точка роста» мәгариф vзәген ачу тантанасы жиһазландырылган кабинетлар буенча экскурсиядән башланды. Традицион тасманы Кадошкино районы депутатлар Советы рәисе В.Н.Кудряшкин белән мәктәп директоры С.Н.Кильдеева кистеләр.
Ромоданово районы Алтар урта мәктәбенен бусагасын беренче тапкыр сигез укучы атлады. Ә барлыгы бу белем йортында 57 укучы укыр. Әлеге уку йортында «Моһим нәрсәләр турында сойләшvләр» («Разговор о важном») барлык сыйныфларда vткән дәрестән тыш чараларында киләчәк турында («Образ будущего. Ко Дню знаний») фикер йорткәннәр. Белем конендә Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбендә, традицияне

дәвам иттеп, укучысы белән бергә директоры Ирфан Касим улы Булатов, vгет-нәсыйхәт cvзләре язылган самолетларны да очыртканнар.
Сентябрьнен беренче дvшәмбесендә дәресләр vткәрv каралмаган иде; мәктәпләрдә дәvләт флагын кvтәрv, шулай ук РФ Дәvләт гимнын башкару, беренче сыйныфлыларын котлау линейкалары тантанасы узды. Кvпчелек уку йортларында «Моһим нәрсәләр турында сойләшvләр» («Разговор о важном») дәрестән тыш чаралар каралган иде. Ә дәресләр 3 сентябрьдә башланды.

**Наилә НАСЫРОВА**